| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Яңа Иглай ав. КАРАР

«21» октябрь 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай торак пунктында авыл җирлеге янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 8 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә .

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Иске Иглай торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

Торак пунктта урамнарны яктыртуны оештыру ёщм карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru  бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/  урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы                                        Р.И. Фәйзуллин